**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

23.05.2024 564-п

Татарстан Республикасы территориясендә Дала Зәе елгасының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларга үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Су кодексы, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законның 32 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары белән расланган Су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә Әлмәт сусаклагычы үзәнендә формалашкан участокта Дала Зәе елгасының яр буе линиясе (су объекты чиге) өлешенең урынын билгеләү буенча эш алып баруга бәйле рәвештә, тәкъдим ителгән материаллар нигезендә боерык бирәм:

1. Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Дала Зәе елгасының су саклау зоналарының һәм яр буе саклык полосаларының киңлеген, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып, әлеге чикләрдә билгеләргә:

су саклау зонасының киңлеге – 200 м;

яр буе саклык полосасының киңлеге: кирегә таба яки яр авышлыгы нульгә тигез булганда – 30 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м, ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градустан артыграк булганда – 50 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (В.А.Долгов):

2.1. Дала Зәе елгасының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турында мәгълүматны Дәүләт су реестрына кертү өчен Су ресурслары федераль агентлыгының Түбән Идел бассейны су идарәсенә җибәрергә;

2.2. су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары чикләре билгеләнгән территорияләргә карата муниципаль, шәһәр округы, торак пунктлар җирле үзидарә органына мәгълүмат җибәрергә;

2.3. Дала Зәе елгасының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турында мәгълүматны Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларга үзгәрешләр кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә (аның территориаль органына) җибәрергә.

3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропагандалау бүлегенә (Е.В.Веселова) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (Р.А.Заһидуллин) әлеге боерыкны, теркәтү өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары О.В.Манидичевага йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков